وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№19 (116). 23 декабрь 2011 / 28-мөхәррәм-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Казандагы беренче мәдрәсәгә – 20 ел!

▷2◁



*Дамир ИСХАКОВ:* "Фәнни нигезебезнең нык булуы кирәк"

▷3◁



*САМАРА ӨЛКӘСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ:* "Без сезгә сокланабыз"

▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

**ӨСТӘЛ ТЕННИСЫ БУЕНЧА ЯРЫШЛАР ҮТТЕ**

18 декабрь көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәте Россия ислам университетында имамнар һәм дини уку йортлары мөгаллимнәре арасында өстәл теннисы буенча шәһәр ярышлары уздырды.

Әлеге ярышта барлыгы 13 команда катнашты: “Әниләр”, “Солтан”, “Ал”, “Фәрхәт”, “Ислам”, “Ризван”, “Әҗем”, “Борнай” мәчетләре, Коръән хафизлары әзерләү үзәге, Россия ислам университеты, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә. I урын Россия ислам университетының ислам дине тәгълиматы факультеты деканы Рамазан Курамшинга, II урын “Әниләр” мәчете имамы Габделҗәлил хәзрәт Касыймовка, III урын “Ризван” мәчете имамы Алан хәзрәт Панаринга бирелде. Җиңүчеләргә дипломнар, медальләр һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

**АССОЦИАЦИЯ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**

20 декабрь көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе шурасының чираттагы утырышы булды. Утырышта ассоциациянең 2012 елга якынча эш планы төзелде:

1) “Хаҗи костюмы” дип аталган дизайнерлар конкурсы үткәрү;

2) “Рамазан–2012” республикакүләм ифтар мәҗлесе оештыру;

3) мохтаҗ кешеләргә “Зәм-зәм суы” тапшыру мөмкинлеген булдыру.

Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе шулай ук төрле семинарлар, хәйрия акцияләре дә үткәрергә ниятли.

Утырышта катнашучылар ассоциациянең офисын (Лобачевский ур., 6) техник яктан яхшырту, аңа фирма стиле кертү, рәсми сайт һәм символика булдыру буенча да фикер алышты.

**ИЛЬЯС УМАХАНОВ БЕЛӘН ОЧРАШУ**

20 декабрьдә Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз РФ Федерация Советы рәисе урынбасары Ильяс Умаханов белән очрашты.

Очрашу барышында 2011 елдагы хаҗ сәфәрләренә нәтиҗәләр ясалды, алдагы елларда хаҗны оештыруның сыйфатын яхшырту һәм бу юнәлештә булган проблемаларны чишү юллары каралды.

**“ХӘЛӘЛ ИНДУСТРИЯ” БЕЛӘН ОЧРАШУ**

20 декабрь көнне Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә Казахстанның “Хәләл индустрия” ассоциациясе җитәкчесе Марат Сарсенбаев белән очрашты.

Очрашуда катнашучылар хәләл продукция җитештерү базарындагы вәзгыять хакында фикер алышты, үзара тәҗрибә уртаклашты, киләчәктә тыгыз хезмәттәшлек итү турында килеште.

Очрашуда шулай ук ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең “Хәләл” комитеты җитәкчесе Динар Садыйков та катнашты.

Моннан тыш, яклар Татарстан һәм Казахстанның “Хәләл” комитетлары арасында бирелә торган таныклыкларны үзара тану турындагы килешүгә кул кую хакында уртак фикергә килде. Аның нәтиҗәсендә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең “Хәләл” комитетында таныклык алган Россия җитештерүчеләре үзләренең хәләл продукциясен – Казахстан, ә Казахстан җитештерүчеләре Россия җирлегендә сата алачак.

***DUMRT.RU***

# ЗАКОНЛЫ МӨНӘСӘБӘТ

**Шушы көннәрдә генә Гражданлык хәле актларын теркәү (ЗАГС) идарәсе хезмәткәрләре үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үтте. 1917 елның 18 декабрендә "Гаилә, балалар һәм гражданлык хәле исәбен алып бару" турындагы декретка кул куела. Бу - дәүләт органнарында теркәлгән гражданлык хәле актлары гына юридик көчкә ия дигән сүз. Хәзерге вакытта илебездә гаилә мөнәсәбәтләре 1995 елның 8 декабрендә кабул ителгән "Россия Федерациясенең гаилә кодексы" нигезендә алып барыла.**

**Соңгы елларда Россиядә рәсми рәвештә теркәлмичә генә яшәү гадәткә керде. Мөселманнарга килгәндә исә, аларның күпчелеге ЗАГСка бармыйча, никах укыту белән генә чикләнә. Әйе, мөселманнарга гаилә корып, бергә яши башлау өчен монысы да җитә. Ләкин, кызганыч, бу мөселман яшьләре арасында зур җавапсызлыкка китерә. Кайберәүләр елына берничә тапкыр никах та укытырга өлгерә. "Талак" әйтәләр дә, Аллаһы Тәгалә алдында үзләрен гаепсез итеп хис итә башлыйлар. Бу хәл "никах" төшенчәсенең әһәмиятле булуына тап төшерә, исламдагы гаилә институтын шик астына ала. Кайбер гаилә башлыклары хатыннарын яшь балалары белән ташлап китә, мал-мөлкәтсез калдыра. "Ни өчен алай эшләдең?" - дип сорасаң, ул: "Аллаһы Тәгалә шулай теләде, минем гаеп юк", - дип җавап кайтара.**

**Шуңа да бүгенге көндә ЗАГСка бару - гаиләгә карата җавапсызлык белән көрәшүнең бердәнбер юлы. Бар кешене дә сансызлар рәтенә кертәсем килми. Безнең арада җаваплы, гаиләсенең киләчәк тормышын кайгыртып яшәүче кешеләр дә бар. Ләкин андыйлар күп түгел. Гражданлык хәле актларын теркәү (ЗАГС) идарәсе, дәүләт органы буларак, кияүгә чыгучы кызларның хокукларын саклап кала ала. Бу нәрсәдә чагыла соң?**


**Беренчедән (монысы иң мөһиме!), ул гаиләдәге балаларның хокукларын яклый. Ир-ат, теләсә-теләмәсә дә, баласын балигъ булганчы материаль яктан тәэмин итеп торырга тиеш. Моннан тыш, аерылган очракта, милек бүлгәндә килеп чыккан сорауларга да җавап табу өчен зур ярдәм булачак. Бу - ислам диненә берничек тә каршы килми, ә киресенчә, бары хуплана гына.**

**Гаилә корырга җитди ниятләре булган ир-ат ЗАГСта теркәлүне алгы планга куя. Аның бу адымы гаиләгә булган игътибары турында сөйли. Күп кенә мөселман гаиләләрендә нәкъ менә шулай эшлиләр дә. Гаиләне рәсми рәвештә теркәү - пәйгамбәребез Мөхәммәт (сгв) заманнарында ук киң таралган гаилә килешүенең бер төре. Язма килешүләрне пәйгамбәребез дә хуплаган. Чөнки төрле кеше була, алар арасында җавапсыз булганнары да җитәрлек. Димәк, рәсми теркәлү - ул йөкләмә булып тора. ЗАГСка бару - милек сорауларын хәл итүче шундый ук рәсми килешү. Бу турыда белеп торырга кирәк. Бигрәк тә мөселман кызларыбызга.**

*Үзәкләшкән дини оешма -*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

# БЕЗ КЕМ?

**Бүгенге көннең ачык бер күренеше булып глобальләшү тора. Глобальләшүдән файда күргән кешеләр аны кешелекнең якты киләчәге дип игълан итә. Ләкин, чынлыкта, монда аерым кеше, гомумән, милләт өчен дә хәвеф-хәтәрләр ята.**



Киләчәк заманның финанс матрицасындагы чималның бер өлеше булу куркынычы - ул джинсыга төренгән, сагыз чәйнәүче, надан һәм бары тик ашау-эчү, уен-көлке турында гына уйлаучы кешеләргә әверелү. Нәкъ менә шул максат белән "Авторитетлар бетсен!" дигән өндәү таратылды. Шуңа да без хәзер дөньяны яңача коруга юнәтелгән, шул технологияләр нәтиҗәсе булган инкыйлаблар тантанасын күзәтәбез. Биредә үз тамырларын искә төшермәгән, бары тик куллануга гына нигезләнгән һәм финанс машинасының тереклеген тәэмин итәргә тиеш булган кешеләр булдыру күздә тотыла. Күрүебезчә, бу сценарий безнең өчен, мөселман булучы милләтләр өчен дә әзерләнгән. "Авторитетлар бетсен!" дигән өндәү бүген безнең фикъһи һәм игътикади мәзһәбләребезгә, бөек (ләкин, имеш, артта калган) мөселман галимнәребезгә каршы юнәлтелгән. Беркемне дә ихтирам итмәүче кешеләргә әйләнгәч, безне башка этап көтә - Аллаһы Тәгаләгә карата булган ихтирамның юкка чыгуы. Төп максат - кешене Аллаһы Тәгалә белән тоташтыручы җепне өзеп, аны хәзерге көнбатыш цивилизациясендәге кебек, паразит кулланучы булдыру.

Ничек итеп сакланып калырга һәм югалмаска соң? Бу сораулар бүген генә тумаган. Безнең татар дин әһелләре моңа көчләп чукындыру вакытларыннан ук җавап эзләгән һәм аңа җавап тапканнар да. Бүген безгә башка, күпкә мәкерлерәк куркыныч яный. Mcdonalds, Adidas, iPad кебек матур төргәкләргә төрелгән рухисызлык дөньяны биләп ала. Ләкин бу авыр шартларда да сакланып калу чарасы бик гади - үзеңнең тамырларыңа кайту кирәк. Безнең дини тамырларыбыз нинди соң?

Беренчедән, бу хәнәфи мәзһәбе. Әбү Хәнифәнең табигыйн булуы һәм аның белемне пәйгамбәребез Мөхәммәт (сгв) сәхабәләреннән алуы сер түгел. Кайберәүләр аңа, имеш, ышанычлы хәдисләр барып җитмәгән, шул вакытта киң таралган секталар ялган хәдисләр чыгарганга күрә, ул хәдисләргә алдан ук үтә дә кискен булган караштa торган, дип әйтә. Чынлыкта исә, Әбү Хәнифәнең бай булуы һәм белем җыяр өчен мөмкинлекләре күп булуы билгеле. Аның имам Мәлик, Җәгъфәр әс-Садыйк һ.б. күп кенә замандашлары белән очрашып фикер алышулары турында күпсанлы риваятьләр бар.

Моннан тыш, хәнәфи мәзһәбе - бер танылган кеше мәктәбе генә түгел, бу, хәзерге заман күзлегеннән чыгып караганда, тулы бер фәнни-тикшеренү университеты. Әбү Хәнифәнең төп максаты булып, мәзһәб нигезләнгән кагыйдәләрне чыгару булган. Соңрак аның иҗтиһад рухында тәрбияләнгән укучылары - Әбү Йосыф, Мөхәммәд, Зөфәр - укытучылары төзегән нигез һәм кагыйдәләргә таянып, Коръән һәм Сөннәттән шәригать кануннарын чыгаруны дәвам иттерәләр. Алга таба дин әһелләренең чираттагы буыны - Тәхави, Әбү әл-Хәсән әл-Кархый, Хәссаф Сәрхаси, Казыйхан - аерым мәсьәләләрне чишү өстендә эшли (алар шулай ук үзләренә кадәр язылган хезмәтләрне дә тикшерә). Алардан соң яшәгән һәр киләчәк буын дин әһелләре дәлилләрне тикшерә, аңлатмалар яза, заманга яраклы яки, алар күзлегеннән чыгып караганда, чыганакларга якынрак булган фәтваларны сайлый.

Нәкъ шундый ук эш хәнәфи гакыйдәсе өлкәсендә дә алып барыла. Мисал өчен, хәнәфи мәзһәбенә нигез салган Әбү Хәнифәгә тоташкан остазлар чылбыры: Әбү Хәнифә ән-Ногманның шәкерте - Мөхәммәд бине әл-Хәсән әш-Шәйбани; аның шәкерте - Әбү Сөләйман Муса бине Сөләйман әл-Җәүҗазани; аның шәкерте - Әбү Бәкер әл-Җәүҗазани; аның шәкерте - Әбү Мансур әл-Матуриди. Алга таба Әбү Хәнифә гыйлеме имам Әбү Мансур әл-Матуриди аша Урта Азиягә, Идел буена һәм ислам дөньясының көнчыгыш районнарына тарала. Күренекле татар дин әһеле Ш.Мәрҗанинең билгеле хәнәфи-матуриди галиме имам ән-Нәсәфи төзегән гакыйдәгә аңлатма (шәрех) язуы да бу мәзһәбнең безнең җирлектә киң таралган булуына дәлил булып тора.

Безнең рухи гореф-гадәтләребезнең тагын бер өлеше булып рухи-әхлакый тәрбия бирүче төрле мәктәпләр тора. Болгар чорында Ясәви мәктәбе үсеш ала, соңрак аны Нәкышбәнди мәктәбе алыштыра. Мәкалә авторы беркемне дә бу мәктәпләрнең берсенә дә керергә өндәми, ләкин борынгы бабаларыбыз мирасына игътибар итмәскә, аларны бидгатьтә һәм ялгышуда гаепләргә ярамый. Билгеле булганча, Габдрахман Утыз Имәни: "Нәкышбәнди тәрикате пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) сөннәтенә иң якын юл, сәхабәләр һәм табигыйннәр юлы", - дип атаган. Моннан тыш, күп кенә мөхтәрәм татар дин әһелләре бу мәктәп шәкерте булган. Могтәбәр Ш.Мәрҗани хәзрәтләре шәех дәрәҗәсенә ирешеп, остазлыкка иҗәзә дә алган. Бәлки, кем дә булса Мәрҗанине дөрес юлдан бармаучы, адашкан, каберләргә табынучы мөшрик, дип атарга батырчылык итәр? Нәтиҗәләр чыгарганда ашыгырга кирәкми. Бүгенге көндә мөселманнар бәхәсләшкән, хәтта бер-берсен үтергән низаглар нигезендә иҗтиһади сораулар ята. Динебез галимнәре ул сорауларга төрлечә җавап кайтара, шуңа күрә дин кардәшләребезгә һәм бабаларыбыз мирасына ихтирамлырак, түземлерәк булырга кирәк. Агачның тамырын киссәләр, ул корый, аның киләчәге булмый...

*Габдулла хәзрәт ӘДҺӘМОВ,*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары*

# "Энҗе" бәйгесендә сәләтле мөслимәләр күпләрне гаҗәпкә калдырды

**17 декабрьдә "Энҗе" I Республикакүләм сәләтле мөслимәләр бәйгесе үтте. Әлеге чара кул эшләре күргәзмәсе формасында Россия ислам университетының актлар залында үткәрелде. Параллель рәвештә мөслимәләр өчен кул эшләре буенча төрле мастер-класслар да оештырылды.**

Бәйгегә Татарстанның төрле төбәкләреннән утызлап катнашучы җыелган иде. Мөслимәләр кул эшләре белән күпләрне сокландырды! Монда сүзләр артык - фотоларга карагач, үзегез дә аңларсыз.

Ә хәзер номинацияләрдә җиңүчеләр белән таныштырып китәбез:

*1) "Иң матур бизәлеш" номинациясендә "Сандыгым" композициясе белән Сөмбел Гаффарова;*

*2) "Ислам һәм иҗат" номинациясендә Чаллыдан килгән кунак - шәмаил чигү формалары әзерләүче Рәсилә Туктарова;*

*3) "Hand-made креатив" номинациясендә декоратив мендәрләр алып килгән Арча кызы Дания Әкъмалетдинова;*

*4) "Файдалы hand-made" номинациясендә кулдан косметика әзерләүче кызлар - Алия Алтынбаева һәм Лилия Галиева;*

*5) "Королева кулинарии" номинациясендә РИУ кызлары командасы;*

*6) "Hand-made королевасы" номинациясендә чигү эшләре белән килгән Мамадыш кунагы - Гүзәлия Гобәйдуллина җиңү яулады!*

Жюри әгъзалары шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова, "Ялкын" журналының бүлек мөхәррире Раилә Сабирова, "Жемчужина веры" хезмәткәре Мөсфирә абыстай иде. Алар барлык эшләрнең дә игътибарга лаек икәнен, урыннар билгеләүнең катлаулы булуын билгеләп үтте.

Җиңүчеләргә дипломнар һәм фотоаппаратлар бүләк ителде, калган барлык катнашучыларга исә истәлекле бүләкләр һәм сертификатлар тапшырылды.

***Чыганак: www.altinurta.ru***







# Казандагы беренче мәдрәсәгә - 20 ел!

**Вөҗдан ирегe бирелгәннән соң, Татарстанда иң беренчеләрдән булып ачылган Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе эшчәнлегенә быел 20 ел тулды. Узган шимбәдә бу юбилей уңаеннан тантаналы мәрасим үткәрелде.**




Әлеге олуг чарага Россиядәге өч абруйлы мөфти - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәизнең, Ханты-Манси автономияле республикасы мөфтие Таһир хәзрәт Саматовның, Мәскәү шәһәре һәм Мәскәү мөфтие Әлбир хәзрәт Кргановның килүләре үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли иде.

Тантаналы мәҗлестә шулай ук ТР Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, ТР Дәүләт Советы депутаты Фәрит Мифтахов, Россия ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, Казан шәһәре имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдин, Татарстан мөфтиятенең уку-укыту бүлеге мөдире Вәлиулла хәзрәт Якупов, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара бәйләнешләр бүлеге башлыгы Ирек Арсланов һәм башка абруйлы затларның катнашулары нур өстенә нур булды, бу чарага үзгә бер җитдилек вә җанлылык өстәде.

Әлеге кичәне Диния нәзарәтенең гомуми бүлек мөдире, әлеге уку йорты ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин алып барды. Мөгаллим Хәйдәр хәзрәт Койрыков Коръән аятьләре укыганнан соң башланган очрашуда җөмһүриятебездә Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәне оештыруда күп көч сарыф кылган Габделхак хәзрәт Саматов белән Кабан арты мәчете имам-хатыйбы Исхак хәзрәт Лотфуллинның исемнәре күп тапкырлар мактап телгә алынды. Бу аңлашыла да. Нәкъ менә шушы ике олуг шәхескә бу изге эшкә нигез салу насыйп була. Габделхак хәзрәт 1988 елда Чистай каласына имам-хатыйб итеп билгеләнгәч, аңа бу төбәктә Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәне оештыру кебек җаваплы вазифа башкарырга туры килә. Әлеге гамәлгә Габделхак хәзрәт бөтен барлыгы, җаны-тәне белән керешә. Ихласлыгы, дини мәсьәләләрне уртачыл караш белән хәл кылуы аркасында ул үзе дә күтәрелә бара. 1991 елда мөхтәсиб итеп билгеләнгәч, ул Казанга килә. Әлбәттә, аның белән бергә мәдрәсә дә Казанга күчә. Менә шул чагында алар Исхак хәзрәт белән бергәләп, мәдрәсәнең эшен тагын да ныграк җанландырып җибәрәләр.

Әлеге тантанлы кичәдә чыгыш ясаучылар күп булды. Анда шактый эшлекле тәкъдимнәр дә яңгырады. Әйтик, Татарстан мөфтие биредә: "Бәлки, киләсе елдан республикабыздагы 11 дини уку йорты остазларына хезмәт хаклары һәм коммуналь чыгымнарны капларлык акча табып булыр. Без үзебез дә шулай булсын дип дога кылабыз, сез дә дога кылып торыгыз", - дип белдерде. Илдус хәзрәт үзе дә шушы мәдрәсәдә укып чыккан икән.

Мөфти Әлбир хәзрәт Крганов та үзенең истәлекләре белән уртаклашты. Ул биредә иң беренче шәкертләрнең берсе булган. "Кабан арты мәчетендә мине Исхак хәзрәт каршы алды. Шәкерт булып укып йөргән чаклар бер дә истән чыкмый икән. Андагы остазларның, өлкән шәкертләрнең җылы карашы әле бүгенгедәй хәтеремдә", - диде Ә.Крганов.

Ханты-Манси мөфтие Таһир хәзрәт Саматов исә үзенең нинди авырлыклар белән чит төбәктә динне күтәрүе хакында бәян кылды. Нибары бер кәгазь белән мәчете дә, намаз укучысы да булмаган чит җиргә 1993 елда килеп төшкән ул. Аны чакырып китергән җитәкче кеше дә Таһир хәзрәтне ике тапкыр кабул иткәч, өченчесендә кабул итүдән баш тарткан. Мондый хәлләрдә кайберәүләр инде кулларын салындырыр, төшенкелеккә бирелер, Казанга кире кайтып китү турында уйлый башлар иде. Тик Габделхак хәзрәтнең улы андый тиз генә җебеп төшә торган затлардан түгел. Ул үзен тиз кулга ала һәм җәмәгатьне туплап, намаз уку гамәленә керешә. Шунда аңа Аллаһының рәхмәте килә: ул мәхәллә халкының ярдәме белән мәчет салдыруга ирешә. Әлбәттә, аңа әтисе Габделхак хәзрәт тә, Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгат хәзрәт тә булыша. "Безнең эштә иң мөһиме - Аллаһның ризалыгы өчен дип гамәл кылырга кирәк. Үзеңә ниндидер матди байлыкка, дәрәҗәгә ирешим дигән максат куеп эшләргә ярамый", - дип кисәтте аеруча залда утыручы шәкертләрне Таһир хәзрәт. Аннары ул бигрәк тә чит төбәкләргә татар имамнарының җитмәвен сөйләде. Аның сүзләренә караганда, ул төбәкләрдә 100 мең мөселман булса, шуның 80 меңен татарлар тәшкил итә икән. Тик алардан 8 кеше дә мәчеткә йөрми. Ә башка милләт вәкилләре аз санлы булсалар да, бердәм рәвештә мәчеткә киләләр һәм имамны үз кешеләре арасыннан куюны таләп итәләр.

Татар конгрессы рәисе Ренат Закировның: "Без элегрәк озак еллар буена дингә битарафлык күрсәттек. Хәзер болай яшәргә ярамаганлыгын аңладык. Дин белән милләтне бергә кушканда гына без көчле булырбыз", - дигән сүзләре күңелемә аеруча хуш килде.

Бу мәдрәсәнең бер үзенчәлеге биредә татар теленә әһәмият бирүдән гыйбарәт. Мәдрәсәдә татар телен укыткан Илһам Фәттахов та чыгыш ясап: "Мин Казандагы РИУның ректоры Рәфыйк әфәнденең университетта студентларга татар телен өйрәтү мөмкин түгел, чөнки анда 46 төбәктән, 6 чит илдән килгән кешеләр укый дигән сүзләре белән килешмим. Ә бит шәкертләр гарәп һәм инглиз телләрен камил өйрәнә. Дәүләт теле булган татар телен өйрәнсәләр, бу һич тә начар булмас иде", - дигән фикерен җиткерде.

Казан мэриясе кунагы Ирек Арсланов бу тантанада эчтәлекле чыгыш ясады һәм мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншинга дин өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен Мактау кәгазе тапшырды. Мәдрәсәнең мөгаллимнәре Хәйдәр хәзрәт Койрыков, Аяз хәзрәт Мингалиев, Зөлфәт хәзрәт Мингалиев, Илдар хәзрәт Ситдыйков, Тимур хәзрәт Ибраһимов, Мөхәммәт хәзрәт Әюпов, Мидхәт хәзрәт Ижбулатов, Якуб хаҗи Әбибуллаев, депутат Фәрит Мифтахов, Фәния абыстай Җәләлиева мөфти хәзрәтләре кулыннан Рәхмәт хатлары алуга иреште.

Бирегә җыелган халык мәдрәсә укытучыларына, остазларга киләчәктә дә дин өлкәсендә уңышлы гамәл кылып, гыйлемле дин әһелләрен, умартачыларны чыгаруларын теләп, якты уйлар, матур хыяллар белән таралышты. 20 ел эчендә мәдрәсә әһелләренең мең биш йөздән артык мөселман укытып чыгаруын исәпкә алсак, болай дип әйтергә тулы нигез бар. Һәм шунысы куандыра: мөфти Илдус хәзрәт Фәизнең сүзләренчә, аларның берсе генә дә мәдрәсә йөзенә кызыллык китермәгән.

***Хатыйп ГӘРӘЙ***
***Чыганак: www.tatar-islam.ru***



*Фото авторның шәхси архивыннан алынды*

# КАМАРЕТДИН ХӘЗРӘТ

## (1890-1963)

Камаретдин Баһаветдин улы САЛИХОВ - күренекле дин әһеле.

Ул 1890 елда Буа районың Альших авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. 1912 елны Буаның "Нурия" мәдрәсәсен тәмамлый һәм шунда мөгаллим булып эшли башлый. 1917-1924 елларда Тәтеш районының Үтәмеш авылында имам-хатыйб вазифаларын башкара. 1920 елның апрелендә ул очраклы рәвештә Буадагы совет хөкүмәтенә каршы чыгышлар вакытына эләгеп, контрреволюцион хәрәкәтләрдә гаепләнеп, кулга алына. Сембер губерниясенең Гадәттән тыш хәлләр комиссиясе тарафыннан ирегеннән мәхрүм ителә. Ләкин бер ел чамасы узгач, аны фәкыйрь гаиләдән, совет хөкүмәтенә яхшы мөнәсәбәттә булуын һәм авылдашларының яклап чыгуын исәпкә алып, иреккә чыгаралар.

1924 елда Камаретдин Салихов Буа районындагы Килдураз авылына күчә һәм анда мулла вазыйфаларын башкаруын дәвам иттерә. Моның белән беррәттән колхозда агач эше остасы һәм умартачы булып эшли. Ләкин 1931-1932 елларда аңа ялган сәяси гаеп тагып яңадан төрмәгә утырталар, ә гаиләсен раскулачить итәләр. Репрессиядән кайткач, ул 1937-1940 елларда Казандагы "Заречье"-да артель бригадиры булып, ә 1940-1945 елларда кибет директоры булып эшли.

1945 елда ул үзенең дини эшчәнлеген яңадан башлап җибәрә. 1945 елдан 1952 елга кадәр Казандагы Мәрҗәни мәчетендә имам-хатыйб вазифаларын башкара, ә 1952 елдан Әстерханның Җәмигъ мәчетендә эшли.

1956 елда Камаретдин хәзрәт Россия башкаласына күчеп килә һәм Мәскәү Җәмигъ мәчетендә имам-хатыйб булып эшли башлый. Узган гасырның илленче еллар ахыры - алтмышынчы еллар башындагы катлаулы чорда ул Мәскәү мөселманнары тормышында зур роль уйный. Нәкъ менә аның тырышлыгы аркасында Хрущев елларындагы дингә каршы актив пропаганда вакытларында Мәскәү мөселманнары мәчете саклап калына, дини эшчәнлек киң колач җәя.

Камаретдин хәзрәткә 1958 елда дин эшләре вәкиле Бесшапошников биргән сыйфатнамәдә (характеристика) болай диелгән: "…Салихов по отношению к советской власти лоялен. За время службы в должности имам-хатыба в Москве ни в чем предосудительном замечен не был. Среди верующих снискал большое уважение". Гарәп телен яхшы белгән, укымышлы Камаретдин хәзрәт көчле оештыручы һәм дипломат сыйфатларына да ия була. Моңа мисал итеп, XX йөзнең илленче елларының икенче яртысында Мәскәү Җәмигъ мәчетенең халыкара эшчәнлегенең зур роль уйнавын әйтергә була. Бу елларда СССРның тышкы сәясәтендә мөселман илләре белән зур мөнәсәбәтләр урнаша. Шул уңайдан, Камаретдин хәзрәт гарәп телендә гарәп илләренә трансляцияләнгән радио тапшыруларында актив чыгышлар ясый, мөселман илләренең илчелекләренә бара, Иран шаһиншаһы Риза-шаһ Пәхләви, Индонезия Президенты Сукарто, Сирия президенты Куатли кебек, күпсанлы чит ил кунаклары белән мәчет диварларында очраша. 1956 елның июль-август айларында ул совет делегациясе составында хаҗга бара. Хаҗдан кайтканда Каһирәдә тукталып, әл-Әзһар университетына укырга керә, андагы галимнәр белән очраша...

Камаретдин Салиховның актив эшчәнлеге дингә каршы дәүләт оешмалары игътибарыннан читтә калмый. Алар 1960 елның июленнән газета-журналларда хәзрәтнең дәрәҗәсен төшерүгә багышланган эшчәнлекне башлап җибәрә. Аларның бу эшләре Камаретдин хәзрәтнең соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. Камаретдин Салихов 1963 елда 73 яшендә дөньядан китә, ул Мәскәүнең Даниил зиратына җирләнә.

Шундый авыр шартларда дингә хезмәт иткән Камаретдин хәзрәтнең рухы шат булсын, Аллаһ аңардан разый булсын!

***Рәшид МАЛИКОВ***
***әзерләде***

### *Дамир ИСХАКОВ:*

# "Фәнни нигезебезнең нык булуы кирәк"

***"Бездә барган дин өлкәсендәге процессларга ачык күз белән карарга кирәк. Мәсәлән, мин үзем элеккеге Татарстан мөфтие (Госман хәзрәт Исхакый. - Н.С.) икенче срокка сайланган вакытта аны нык кына тәнкыйтьләгән идем. Мин Госман хәзрәт 2002-2006 елларга мөфти итеп сайланган вакытта катнаштым. Ул беренче срогында яхшы гына эшләгән иде. Тик икенче срогында эшләр начарайды", - дип башлады үз сүзен тарих фәннәре докторы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетындагы этнологик-мониторинг үзәге җитәкчесе Дамир ИСХАКОВ.***

**- Ул кайсы якка начарайган иде?**

- Дөресен генә әйткәндә, традицион исламны үстерү юнәлеше буенча эш начар барды. Чөнки безнең татарда традицион рәвештә саклаган исламның үзенең үзенчәлекләре бар. Ул халкыбызның тарихы һәм мәдәнияте белән бик нык бәйле. Менә шуларга таянасы урында, безгә читтән ят булган йогынтылар үтеп керә башлады. Мин, мәсәлән, үзем читтән керүчеләрне "ваһһабилар" (дошманнар. - Д.И.) дип сүкмәс идем. Минемчә, аларны да аерып карарга кирәк. Согуд Гарәбстаны - ул мөстәкыйль ил, андагы гарәпләр исламны нинди вариантта тотарга телиләр икән, шулай тотарга тиешләр. Безнең анда катнаш юк. Шуңа күрә мин аларны (Согуд Гарәбстанында яшәүче халыкны. - Д.И.), мәсәлән, мөселманнар буларак ихтирам итәм. Әмма алар экспорт рәвешендә үз вариантларын кертеп, без менә шулай яшәргә тиеш, дип, аны безгә көчләп тагарга уйлыйлар икән, моңа без каршы торырга тиешбез. Чөнки безнең үзебезнең ата-бабаларыбыздан калган исламның үзенчәлекләре халкыбыз тарихы белән бәйле. Мин күптән түгел генә "Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында сәедләр институты" (Исхаков Д.М. Институт сейийдов в Улусе Джучи и позднезолотоордынских тюрко-татарских государствах. - Казань: Изд-во "Фэн" АН РТ, 2011. - 228 с.) дигән китап яздым. Әлеге хезмәтемдә Алтын Урда чорындагы барлык халыкларның исламлашу мәсьәләсен тикшерүне бурыч итеп куйдым. Шунысы ачык күренә: безнең җирле ислам суфый тәрикатләре - Ясәвия һәм Нәкышбәнди тәрикате белән бәйле. Безнең, мәсәлән, Казан ханлыгының соңгы сәеде, данлыклы Кол Шәриф (ул, барыбызга да билгеле булганча, Казан Кремле эчендә басып алучылар белән сугышып үлә) - ул Ясәвия тәрикатенең бер вәкиле. Бу хакта шактый мәгълүматлар бар.

**- Ә Нәкышбәнди тәрикате кайчан барлыкка килә?**

- Ул Ясәвия тәрикате эченнән үсеп чыгып, бераз соңрак барлыкка килә (якынча XVI йөзнең икенче яртылары. - Д.И.), ягъни Казан ханлыгы таркалганнан соң гына көчәя башлый. Иң кызыгы шунда: безгә Ясәвия тәрикатенең үтеп керүе - бернинди Идел Болгарстаны белән дә бәйле түгел. Ул - Алтын Урда чорында барган процесслар һәм бу чорда яшәгән татар элитасының ислам динен кабул итүе белән бәйле. Исламны алып килгән кешеләрнең барысы да Харәземнән килүчеләр. Һәм безне төп тарихи җепләр Харәземгә тарта. Шуннан чыгып фикер йөрткәндә, безнең традицион исламга булган карашыбыз әле дә булса ялгыш булып кала бирә. "Традицион ислам" дигән вакытта, аны безгә үзебезнең тарихи чыганакларга таянып күтәрергә кирәк. Иң кызганычы шул: читтән кергән йогынтыларга каршы тору өчен, традицион исламны күтәрергә кирәк дип тотындылар, ә бит, дөресен генә әйткән вакытта, татарның традицион исламы буенча бер фәнни хезмәт тә юк. Мин быелдан башлап шушы проблемаларны өйрәнү өчен бер аспирант алдым. Максатыбыз - беренчеләрдән булып татарның традицион исламын төрле яклап тасвирлау.



**- Ә татарның традицион исламы турында нинди күзаллаулар тудырырга мөмкин?**

- Аның бик күп үзенчәлекләре бар, чөнки ислам дине безгә кергәннән соң, ул тарихи рәвештә үскән, аны җирле элементларны үзенә керткән. Мин моңа бер мисал китереп уза алам. Әйтик, элек-электән татарларда Мәүлед бәйрәме булган. Ә бит бу бәйрәм гарәпләрдә алай ук таралмаган. Ул - бездә, төрекләрдә һәм Урта Азиядә бар. Татарларда аеруча да көчле. Бу мәсьәләләр буенча үз вакытында композитор Мәсгудә Шәмсетдинова бер фәнни хезмәт язган иде. Шуннан күренгәнчә, Мәүлед бәйрәмен үткәрү - бер үк вакытта, ул суфыйчылык белән дә бәйле. Аны шуннан башка аерып карап булмый. Аннан соң бит безнең күп кенә изгеләр күмелгән урыннар бар. Татар галимнәренең исәбе буенча, Идел буе төбәгендә ике йөзгә якын изгеләр күмелгән урын бар. Изгеләрнең шәхесен тикшерә башлыйбыз икән, бу очракта да без суфый тәрикате вәкилләренә яисә шулар белән бәйле шәехләр күмелгән урыннарга килеп чыгачакбыз. Миңа Биләр янындагы Мәлүм хуҗаның кабере (аны хәзер Изгеләр чишмәсе урыны дип атыйлар. - Д.И.) янында халыкның акчалар ташлап, ярыммәҗүси "обряд"лар ясавы бик тә сәер һәм көлке тоела. Бу бит наданлыктан килеп чыга. Әмма Мәлүм хуҗа бит реаль шәхес булган. Аның артыннан китсәң, бик кызык әйберләргә барып тоташуың бар. Минем уйлавымча, ул - монголларга кадәр ислам динен кабул иткән кыпчакларның бер лидеры. Тарихта билгеле булган Балынбәк күмелгән анда. Аны шулай "хуҗа" дип зурлап (билгеле булганча, анда бер дөрбә дә булган. - Д.И.) күтәреп чыгу - ул шушы монголларны исламлаштыруда катнашуы белән бәйле. Мин бу күренешләрне читтән генә булса да күзәтеп киләм. Безнең Болгардагы исламны гына күтәрүебез - тамырдан ялгыш. Чөнки Алтын Урда чорында булган процессларны өйрәнмичә торып, шуннан башка безгә үзебезнең татар булып калып, ничек иттереп мөселман булып яшәвебезне аңлау бик кыен. Аны бөтен җирлектә карарга кирәк. Мин моңа аеруча басым ясап әйтәм, чөнки татарда булган исламның тарихи ягы бик начар өйрәнелгән. "Безнең борынгы болгар бабаларыбыз исламны кабул иткән дә, без шуннан соң мөселман булганбыз" дигән карашны гына сукалап йөрү - ул фәнгә бернинди дә яңалык бирми. Әйтерсең лә, шуның белән ислам дине тукталган?! Мин тарихчы-этнограф буларак шуны әйтә алам: болгар чорындагы исламның нинди булуы турында бер генә мәгълүмат та сакланмаган. Аларның мөселман булулары турында билгеле - монысы бәхәссез, әмма кайсы тәрикатькә караган, андагы ислам үзенчәлекләре нинди булган, бу хакта бернәрсә дә юк. Кызганыч. Хәтта менә Болгар шәһәре урынындагы сәхабәләр күмелгән каберлек (бу хакта ислам динен алып килүчеләр дигән легендалар да бар. - Д.И.) тә исбат ителгән әйбер түгел бит. Мин уйлыйм, бәлки алар Алтын Урда чорында килгән шәхесләрдер. Чөнки шул вакытта да сәхабәләр килгән, алар Алтын Урданың элитасын исламга күчергән вакытта катнашкан. Аннан соң тагын бер кызыклы әйбер бар. Галимнәр шундый фикергә килде: болгар исламы - ул бик сугышчан ислам булган. Ул вакытта бөтен тирәякта мәҗүсиләр булган, алар хәрби көчләр кулланып, мәҗүсиләргә каршы сугышлар алып барган. Ягъни, Алтын Урда чорындагы кебек тыныч мөнәсәбәтләр беркайчан да булмаган. Алтын Урда чорында диннәр бер-берсе янында яшәп, анда динара мөнәсәбәтләр тыныч булган. Без бары тик Болгар исламын гына күтәрә башласак, аның бу ягы да килеп чыгачак. Бу хакта әле уйлаган кеше дә юк. Андый әйберләр бик күп. Шуңа күрә, "традицион ислам" дип сөйләшә башлыйбыз икән, әүвәл безгә аның нинди формаларда яшәгәнлеген өйрәнергә кирәк булачак. Аеруча аның гореф-гадәтләргә катнашкан өлешләрен. Әйтик, бездә кеше үлгәч, аның "өчесе"н, "җидесе"н, "кырыгы"н билгеләп үтү бар бит.

**- Ә ни өчен безнең бу йолаларга гарәпләр каршы чыкты соң?**

- Билгеле, бу мөселман гадәте түгел. Ул - безнең төрки бабалардан кергән гадәт. Чынлыкта, ислам бит аңа каршы килми. Бәлки без бу юл белән совет чорында исламны саклап та калганбыздыр әле. Моны инкарь итәргә кирәк түгел, моны бары тик аңларга кирәк. Аның исламга турыдан-туры бәйле һәм аңа бәйләнмәгән өлеше бар. Әмма аларны аңлау өчен ул мәсьәләләрне иң башта өйрәнергә кирәк, аннан соң гына халыкка аңлатырга кирәк. Безнең халык белми бит ул нәрсәләрне. Югарыда әйткәнемчә, Биләр шәһәрчеге янында кешеләр Изгеләр күмелгән урынга дип чишмәгә акча аталар. Билгеле, бу - мәҗүсилек. Чөнки анда яткан кеше бернинди дә мәҗүси түгел. Ул - фәкать мөселман юлбашчыларының берсе. Элек халык шул шәхесне искә алырга йөргән. Суфыйлар белән бәйле булганга күрә, ул шул вакытта суфыйчылык звеносы булып торган. Халык хәзер боларның бөтенесен дә оныткан. Шуны онытканга күрә, шуңа шулай итеп барып табынырга кирәк икән дип уйлый инде. Бу бит наданлык дигән сүз. Шул ук Изге Болгар җыены вакытында да Җәмигъ мәчет баганасы янында халык шуңа тотынып әйләнә. Шунда әйләнүче хатын-кызлар: "Монда әйләнсәң, бала була икән", - ди. Әмма, әйләнү - ул бит суфый зикрыннан калган бер элемент кына бит. Традициясе калган, тик безнең очракта халык нәрсә эшләгәнен аңламыйча хәрәкәт итә. Ул бала туу белән берничек тә бәйле түгел. Менә шундый әйберләрне өйрәнеп, халыкка аңлатырга кирәк. Безнең нинди традицион элементлар бар, ул тарихи яктан кайчан килеп чыккан һәм ул нәрсә белән бәйле? Надан рәвештә, күзне ачып карамыйча кереп китәргә кирәк түгел. Аңлап хәрәкәт итәргә кирәк. Бу юнәлештә безнең эш бик аз эшләнгән. Шуңа күрә, Диния нәзарәтләре читтән кергән йогынтыларга каршы көрәшергә уйлый икән, башта шушы якны фәнни өйрәнү кирәк. Шул вакытта гына без үзебезнең исламның үзенчәлекләрен дөрес аңлаячакбыз. Бу хакта безнең бүгенге көндә чыгарып сала торган бер генә хезмәтебез дә юк. Эш анда гына да түгел, безгә дин белгечләре язган китапларның эчтәлеген дә яңадан карарга кирәк. Татар дин белгечләре (Мәрҗани, Бигиевлар һ.б.) язган йөзгә якын әһәмиятле китап бар, дип әйтәләр. Шул йөз китапның бишесе генә яңадан чыгарылды. Әле чыгарылды гына бит әле ул, әмма аның эчтәлеге турында уйланырга кирәк, аңа хәзерге заманча трактовка бирергә кирәк. Моңа әле тотынган кеше дә юк. Шуңа күрә: "Без мөселманнар, без белемле", - дип әйтүебез, ул безнең бабаларыбыз эшләгән эшкә генә таянып, үзебез аның нәрсә икәнлеген аңламыйча гына хәрәкәт итү ул. Бу - шапырынуның бер төре. Безгә башка милләтләр алдында мактанганчы, әүвәл үзебезнең кем икәнлегебезне аңларга кирәк, ә аның өчен бөтен шушы фәнни мәсьәләләрнең эченә кереп чуммыйча булмый.

**P.S.: шушы көннәрдә генә олуг галимебез Дамир Исхаковның гомер бәйрәме - 60 яшьлек юбилее булды. Без аны ТР мөселманнары Диния нәзарәте исеменнән ихлас күңелдән тәбрик итәбез. Аңа ныклы сәламәтлек, гаилә бәхете һәм зурдан-зур иҗади уңышлар насыйп булуын телибез!**

***Әңгәмәдәш -***
***Нияз САБИРҖАНОВ***

# САМАРА ӨЛКӘСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ: "Без сезгә сокланабыз"

**Әңгәмәбез - Самара өлкәсенең Камышлы, Келәүле, Исаклы районнары имам-мөхтәсибе, Самара өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәтендәге Президиум әгъзасы Габдулла хәзрәт МӨХӘММӘТКӘРИМ белән.**



**- Самара өлкәсендә динебезнең торышы ничек? Шул хакта сөйләп уза алмассызмы икән.**

- Мин 1994 елда Самара өлкәсендәге Гали авылы мәдрәсәсендә белем алып чыкканнан соң, имам булып эшли башладым. Бүгенге көнгә кадәр шул вазифамны уңышлы гына үтәп киләм. Мин эшли башлаганда өлкәбездә 24 мәхәллә теркәлгән иде, хәзерге вакытта исә аларның саны - 96. Диния нәзарәтебез эшли башлаганнан бирле (1995 елдан) мөфти вазифасын Вәгыйзь хәзрәт Яруллин алып бара. Без аның эшчәнлегеннән бик тә канәгать, ул үзенең тырышлыгы белән мөселманнар белән генә түгел, башка конфессияләр белән дә җылы элемтәләр урнаштыра алды. Күптән түгел - ноябрь аенда гына провослав дин әһелләре белән семинар уздырдык. Бу - безнең өчен бик тә шатлыклы күренеш. Алар белән уртак тел табып, бер-беребезгә ярдәм кулы сузып, фәнни конференция оештырдык. Диннәр, милләтләр үзара дус-тату яшәү сәбәпле, өлкә хөкүмәте 16 ел дәвамында инде үз бюджетыннан дини корылмаларны төзекләндерү өчен акчалата ярдәм күрсәтеп килә. 2008 елда гына да 130 миллионнан артык акча бүлеп бирелгән иде. Без моны һәрбер мәхәлләгә ремонт эшләре алып бару өчен сарыф иттек. Кызганыч, 96 мәхәллә арасында яшь имамнарыбыз бик аз. Егермедән артык мәхәлләдә генә яшь имамнарыбыз эшли. Калган мәхәлләләрдә - үз тырышлыгы белән динебезне өйрәнеп, олылайган көннәрендә үзләрен дингә багышлаучы затлар хезмәт куя. Без аларның фидакарьлегенә сокланабыз, алар мәчетләребез ябылмасын, динебез югалмасын диеп үзләренең бар тырышлыгын куя.

Киләсе елга Гали авылында мәдрәсәбез ачылуга 20 ел тула. Шулай ук Самара Җәмигъ мәчете каршында да "Нур" мәдрәсәсе эшләп килә. Татар телендә берничә газета бастырабыз. Диния нәзарәтендә әүвәл "Әссәламегаләйкем" дигән газета чыгып килде, хәзерге вакытта "Ислам-Нур" дигән газетабыз нәшер ителә. Ул аена ике мәртәбә дөнья күрә. Беренче ике табак битле чыгырылышы - рус телле укучылар өчен булса, дүрт табак битлесе татар телендә вәгазьләр, репортажлар белән басыла. Мәхәлләләребезнең тарихын чагылдырган китап бастырдык, аны бу килүебездә Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәизгә дә бүләк иттек.

**- Самара өлкәсе татар имамнарына кытлык кичермиме?**

- Безнең 96 мәхәлләбезнең һәркайсында да диярлек татар имамы эшли. Әмма үзгә милләттән булган мөселман кардәшләребезнең (чеченнар, азәрбайҗаннар һ.б.) күпчелеге намазга йөрүче кайбер мәчетләрдә вәгазьләр рус телендә бара. Әмма күп мәчетләрдә вәгазьләр татар телендә сөйләнелә. Шулай ук җомга вәгазенең яртысын татар телендә, калган өлешен русча алып барган берничә мәхәлләбез дә бар.

**- Татарстанда үтә торган нинди дини чаралар сездә зур кызыксыну уята?**

- ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм Бөтендөнья татар конгрессы уздырып килгән Изге Болгар җыенында һәм татар дин әһелләре форумында актив катнашып киләбез. Соңгысында катнашу өчен үткән елны да, быел да өлкәбездән иллеләп имам килгән иде. Без Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән күптәннән таныш. Казан - милли мәркәзебез булганлыктан, ул безгә һәрвакыт зур үрнәк булып тора. Без - Самара өлкәсе мөселманнары, сезгә сокланабыз. Киләчәктә дә бергә-бергә ярдәмләшеп эшләрбез, дип уйлыйм.

**- Татарстаннан тагын нинди тәэсирләр алып кайтып китәсез?**

- 20 декабрь көнне мөфти Илдус хәзрәт Фәиз белән очраштык. Нәтиҗәдә, безнең теләк-максатлар бер үк икән. Без дә үзебезнең өлкәбездә халкыбызның традиция, гореф-гадәт, йолаларын саклап калу, аларны кайтару, яшь буынга сеңдерү буенча киң колачлы эш алып барабыз. (Казан шәһәрендә балалар өчен үткәрелгән дини конкурсларда да без инде дүртенче мәртәбә катнашып киләбез.) Без дә кеше вафат булганнан соң аның рухына Коръән укыту ("өчесе", "җидесе", "кырыгы"), Мәүлед бәйрәмен үткәрү кебек мәҗлесләребезне бар тулылыгы белән саклanып калуга ирештек. Яшермичә әйтергә кирәк, Татарстан киләчәктә дә безгә күп яктан үрнәк булып калыр, Иншә Аллаһ.

**Әңгәмәдәш - Нияз САБИРҖАНОВ**

# БӘХЕТ АЧКЫЧЛАРЫ

**Һәр кешенең кайчан да булса уйландырырга мәҗбүр иткән темалары шактый. Ул кайвакыт йокыларны качыра, ашаудан калдыра, ниндидер хисләр белән тулган тормышны тагын да баета. Хәзер сүзем - "Хатын-кыз бәхете" турында. Күпме язучыларның әсәрләрендә чагылган, бары соклану һәм гүзәллек кебек хисләр тудырган хатын-кызларыбыз! Нәкъ менә аларга һәрвакыт терәк һәм назга тулып торган бәхетле тормыш кирәк.**

Чөнки алар батыр ирләр табып биргән малны саклаучы, назга сусаган күңелләрне өмет һәм шифа белән тулыландыручы һәм, әлбәттә, гаилә учагына җылы биреп торучы затлар!

Шул нисбәттән Татарстанның мөселман яшьләре берлеге барлык күркәм затларыбыз өчен "Бәхет ачкычлары" дигән тренинглар курсы оештырды. Ул Казандагы Мәрҗәни мәчетендә үтте. Рүзәл Әхмәдиев җитәкчелегендәге әлеге оешма күптән түгел генә эшли башлады һәм беренче эш итеп ул мөселманнар арасында "Quest muslims" (Квэст муслимс) дип аталган интеллектуаль уен үткәрүе белән танылды.

Гүзәл затларыбыз бу тренингка без көткәннән дә күбрәк килде. Йөздән артык кызларыбыз биредәге тренинг курсларын узды. Әйтәсе килә, бу тренинглар аларны чыннан да кызыксындырды һәм аңа ихтыяҗ зур иде. Кызларыбыз монда хатын-кыз гаиләдә, җәмгыяттә, ире белән, ата-анасы һәм балалары белән дигән темаларга вәгазьләр генә тыңлап калмады, ә төрле тренингларда актив катнашып, үзләрен ачты һәм, миңа калса, бу аларның күзаллауларын да бераз үзгәртте һәм баетты. 7 декабрь көнне башланып киткән курсларда беренче булып кызларыбызга үгет-нәсихәт кылырга Габдрахман хәзрәт Наумов килде. Беренче көннән үк кызларга бер-берсе белән танышып дуслашырга, аралашырга Казан шәһәрендәге Совет районының "Ел укытучысы" исемен алган Чекмарева Екатерина Владимировна булышты. Алты көн дәвамында кызлар белән, иң яхшы нәсихәт әйтүчеләр һәм Казанның иң яхшы профессиональ пешекчеләре, косметолог һәм докторлары мастер-класслар һәм төрле фикер алышулар үткәрде.

Ә ябылу тантанасына Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз дә килгән иде. Ул оештыручыларга чын күңелдән рәхмәт әйтте, укытучы һәм остазларга рәхмәт сүзләре җиткерде. "Мондый курслар ешрак узса яхшырак булыр иде, чөнки гүзәл затларыбыз гына түгел, без барыбыз да һәрвакыт белем алуда һәм үсештә", - диде Илдус хәзрәт.

Чыннан да, беренче тапкыр оештырылган курсларның әле кытыршы яклары да булгандыр. Ни генә дисәң дә, беренче коймак төерле була бит. Шуны әйтәсе килә: бу курслар ихластан гүзәл затларыбыз өчен оештырылды, юкка гына әйтмәгәннәр бит: һәр эшнең дә нияте дөрес булып дәвамлы булуында иң зур савап һәм әҗердер...



***Гөлсәрия НӘБИУЛЛИНА, Мөселман яшьләре берлеге активисты***

# Аллаһшөкер Пашазадә Казанга килде

**ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов БДБ мөселманнары шурасы рәисе - Кавказ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Аллаһшөкер Пашазадә белән очрашты.**





Р.КАДЫЙРОВ фотолары

Татарстанның Хөкүмәт йортында узган очрашуда ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз, ТР Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин һ.б. катнашты.

ТР Президенты матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, яклар өммәт тормышы белән бәйле мәсьәләләр, төрле милләт вәкилләре яши торган төбәкләрдә конфессияара мөнәсәбәтләрне саклау буенча фикер алышты.

Билгеле булганча, Аллаһшөкер Пашазадә ТР мөселманнары Диния нәзарәте үткәргән "Ислам - терроррчылыкка каршы" дип исемләнгән фәнни-гамәли конференциясендә катнашу өчен килгән иде.

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 24.12.2011 | 7:42 | 09:12 | 13:02 | 15:09 | 16:13 | 17:43 |
| Якшәмбе | 25.12.2011 | 7:42 | 09:12 | 13:02 | 15:10 | 16:13 | 17:43 |
| Дүшәмбе | 26.12.2011 | 7:43 | 09:13 | 13:02 | 15:11 | 16:14 | 17:44 |
| Сишәмбе | 27.12.2011 | 7:43 | 09:13 | 13:02 | 15:11 | 16:15 | 17:45 |
| Чәршәмбе | 28.12.2011 | 7:43 | 09:13 | 13:02 | 15:11 | 16:16 | 17:46 |
| Пәнҗешәмбе | 29.12.2011 | 7:43 | 09:13 | 13:02 | 15:12 | 16:17 | 17:47 |
| Җомга | 30.12.2011 | 7:43 | 09:13 | 13:02 | 15:13 | 16:18 | 17:48 |
| Шимбә | 31.12.2011 | 7:43 | 09:13 | 13:02 | 15:13 | 16:19 | 17:49 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №19 (116) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-519.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 22 декабрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**